РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ
СТАРОТИНЧАЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ТИНЧӘЛЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

10.06.2026 №14-1

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Иске Тинчәле авыл җирлеге Советының 2023 елның 26 апрелендәге 70-3 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Иске Тинчәле авыл җирлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, әгәр бу белешмәләрне бозу җитди булмаса, дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен җаваплылык чаралары куллану турында карар кабул итү тәртибен раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законнар, «Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру тәртибе хакында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы, «Муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» 2017 елның 19 июлендәге 57-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Иске Тинчәле авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Иске Тинчәле авыл җирлеге Советының 2023 елның 26 апрелендәге 70-3 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Иске Тинчәле авыл җирлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, әгәр бу белешмәләрне бозу

җитди булмаса, дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен җаваплылык чаралары куллану турында карар кабул итү тәртибен раслау хакында» карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. Буа муниципаль районы Иске Тинчәле авыл җирлеге Советының 2023 елның 26 апрелендәге 70-3 номерлы карарына кушымтаның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33 - ФЗ номерлы Федераль законның 29 статьясындагы 4 өлеше нигезендә муниципаль вазыйфаларны биләүче, керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән затларга карата түбәндәге җаваплылык чаралары кулланыла:

1) кисәтү;

2) аның вәкаләтләре чоры туктатылганчы депутатны, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Иске Тинчәле авыл җирлеге Советы әгъзасын, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Иске Тинчәле авыл җирлеге Советындагы вазыйфасыннан азат итү, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Иске Тинчәле авыл җирлеге Советындагы вазыйфаларын биләү хокукыннан мәхрүм итү;

3) вәкаләтләре чоры туктатылганчы вәкаләтләрне даими нигездә башкару хокукыннан мәхрүм итеп, вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан азат итү;

4) Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Иске Тинчәле авыл җирлеге Советында аның вәкаләтләре чоры туктатылганчы вазыйфаларын биләүне тыю;

5) вәкаләтләрне вәкаләтләре чоры туктатылганчы даими нигездә башкаруны тыю.

1.2.Буа муниципаль районы Иске Тинчәле авыл җирлеге Советының 2023 елның 26 апрелендәге 70-3 номерлы карарына кушымтаның 3 пунктындагы 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күрсәтелгән мәсьәләне карау өчен нигез булып Татарстан Республикасы Рәисенең муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата җаваплылык чараларын куллану турында «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 20.03.2025елдан № 33 - ФЗ Федераль законның 29 статьясындагы 3 өлешендә каралган җаваплылык чараларын куллану турында гаризасы тора.».

2. Әлеге карар басылып чыккач законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырылырга тиеш (https://pravo.tatarstan.ru/), шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (http://buinsk.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының
Иске Тинчәле авыл җирлеге башлыгы С.Р.Хәсәнов